СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**14.12.2018**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 217**

Зеленодольск шәһәре Советының «2017 елның 1 гыйнварыннан Зелнодольск шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында " 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 9 июлендәге 196 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 7 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Зеленодольск шәһәре Советының «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә физик затлар милкенә салым турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карарына (2018 елның 9 июлендәге 196 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 бүлегенең 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«фатирлар, фатир өлешләре, бүлмәләр»;

2) 2 пунктның 2 бүлегенең 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре»;

3) 2 пунктның 2 бүлегенең 6 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"әлеге пунктның 3 бүлегендә күрсәтелгән гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән, салым салу объектларында урнашкан урыннар".

2. Әлеге карарның 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарату гамәлдә.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга, шулай ук, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Карар салым законнары нигезендә үз көченә керә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**